ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН БИШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

№ 129 16.08.2018 ел

**Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советына Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советына җирлекнең генераль планын, җирлекнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документлар, җирлекләрне проектлаштыруның җирле нормативларын раслау һәм (яки) үзгәрешләр кертү буенча вәкаләтләрен тапшыруны тәкъдим итәргә.
2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы** **Д.В.Насертдинов**